| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.10.2020 пгт. Рыбная Слобода №206пи

Татарстан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 октябрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 15п. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.
2. Проектны эшләү вакытын 2020 елның 31 декабренә билгеләргә.
3. Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына проектны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адрес буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов